Республикада озак яшәvчеләрне санадылар. Мордовиястатта хәбәр итvләренчә, 2019 ел башында тобәктә 90 яшьтән һәм аннан да олкәнрәк 4514 кеше булган. Аларнын кvбесе хатын-кызлар - 3825. Ир-атлар биш тапкыр кимрәк - барлыгы 689.
«Мордовиянен озын гомерле кешеләре саны 90 яшьтән алып 94 яшькә кадәр (3700 кеше); 95 яшьтән 99га кадәр - 668, 100 һәм аннан да олкәнрәк - 146 кеше», - дип сойләделәр статистика хезмәтендә. Ел башына Мордовиядә барлыгы 795 мен 579 кеше яшәгән. Ягъни 90 яшькә кадәр Мордовиядә халыкнын бер проценты да яшәми.

Олы яшьтәгеләрне хормәт итәбез, тәрбиябез шундый. Шулай, Торбеево районы Татар Юнки авылында яшәvче Сәидә Хәсән кызы Утешева vзенен 90 яшьлек юбилеен билгеләп vтте. Ветеранны туган коне белән район башлыгы урынбасары Н.Киреев, Торбеево районы буенча халыкны социаль яклау учреждениесе директоры урынбасары М.Шумкин һәм авыл администрациясе урынбасары Альфия Әхмәт кызы Урманчеева котладылар. Алар ана Россия Президенты В.Путиннын Котлау хатын, бvләкләр һәм чәчәкләр тапшырдылар, озак еллар намуслы хезмәте очен рәхмәт белдерделәр, сәламәтлек һәм озын гомер теләделәр.
Сәидә Хәсән кызы Утешева зур татар гаиләсендә vсә һәм тәрбияләнә. Анын әнисе Шәрифә Усман кызынын 12 баласы булган, шуларнын сигезе vсеп картлыкка кадәр гомер иткән. Сәидә алтынчы бала буларак туа һәм озын матур гомер итә. Кызганычка каршы, анын бертуган братлары һәм сенелләреннән беркем дә бvгенге конгә кадәр яши алмаган, бакыйлыкка кvчкәннәр инде.
Боек Ватан сугышы башланганда бvгенге юбилярга нибары 12 яшь булган. Ил очен авыр вакытта Сәидә Хәсән кызы vзенен туганнары белән бергә фронтка торле ярдәм кvрсәтергә тырышкан. Ана колхоз кырларында эшләргә, дару vләннәре жыю белән шогыльләнергә, фронтка жибәрергә дип жылы әйберләр бәйләргә (бу һонәре гомер буена юлдаш булып калган; ул матур-матур кофталар, кvлмәкләр һәм башка әйберләрне гомере буе бәйләгән) туры килгән. Шулай жинvне якынайталар бергәләп. Сугыш елларыннан сон, тыныч тормыш тозv дә жинелләрдән булмый, әмма халык шатланып алга атлый, гаилә кора, балалар асрый. Сәидә Хәсән кызы, тормыш иптәше Митхәт

Исмәгыйль улы белән матур гаилә коралар. Бер-берсе белән балачактан ук таныш булган яшьләр 1955 елда өйләнешәләр һәм инде 64 ел бергә матур гына яшиләр. Алар оч кыз тәрбияләп vстергәннәр, әбиләрен һәм бабайларын шатландырып биш оныклары һәм дvрт оныкчыклары vсәләр. Яшьләре олы булу аркасында, Сәидә Хәсән кызы белән Митхәт Исмәгыйль улы vзләренә хезмәт кvрсәтә алмыйлар инде. Шуна Утешевларнын олкән кызлары Зәкия, дvрт ел элек, олкән яшьтәге ата - аналарын карау очен, Мәскәvдән туган авылы Татар Йонәсенә кvчеп килгән. Калган балалары һәм оныклары Мәскәvдә яшиләр, әмма момкин кадәр ешрак яраткан әниләренә һәм әбиләренә кунакка килергә тырышалар. Шуны да билгеләп vтәргә кирәк, аларнын зур тату гаиләсендә татар милли гореф-гадәтләрне хормәт итәләр һәм саклыйлар.

Наилә Насырова